КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 25 июль г.Казань № 623

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 14 июнь, 492 нче; 2014 ел, 25 сентябрь, 678 нче; 2014 ел, 9 декабрь, 962 нче; 2014 ел, 31 декабрь, 1090 нчы; 2015 ел, 2 февраль, 54 нче; 2015 ел, 24 апрель, 279 нчы; 2015 ел, 7 август, 576 нчы; 2015 ел, 24 август, 619 нчы; 2015 ел, 26 август, 620 нче; 2015 ел, 16 октябрь, 771 нче; 2015 ел, 11 ноябрь, 844 нче; 2016 ел, 19 гыйнвар, 19 нчы; 2016 ел, 11 февраль, 85 нче; 2016 ел, 30 апрель, 274 нче; 2016 ел, 14 май, 315 нче; 2016 ел, 25 май, 346 нчы; 2016 ел, 21 июнь, 420 нче; 2016 ел, 22 август, 580 нче; 2016 ел, 29 август, 597 нче; 2016 ел, 3 октябрь, 703 нче; 2016 ел, 19 октябрь, 761 нче; 2016 ел, 26 октябрь, 784 нче; 2016 ел, 16 декабрь, 938 нче; 2016 ел, 29 декабрь, 1047 нче; 2016 ел, 31 декабрь, 1093 нче; 2017 ел, 20 гыйнвар, 18 нче; 2017 ел, 16 март, 150 нче; 2017 ел, 15 май, 286 нчы; 2017 ел, 7 июнь, 353 нче; 2017 ел, 13 июль, 481 нче; 2017 ел, 28 июль, 528 нче; 2017 ел, 5 сентябрь, 632 нче; 2017 ел, 4 октябрь, 758 нче; 2017 ел, 11 ноябрь, 862 нче; 2017 ел, 6 декабрь, 935 нче; 2017 ел, 7 декабрь, 947 нче; 2018 ел, 26 февраль, 109 нчы; 2018 ел, 9 июль, 560 нчы;

2018 ел, 1 сентябрь, 738 нче; 2018 ел, 12 ноябрь, 990 нчы; 2018 ел, 24 декабрь, 1212 нче; 2019 ел, 6 август, 647 нче, 2019 ел, 9 октябрь, 896 нчы; 2020 ел, 28 гыйнвар, 36 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2014 – 2022 елларга» сүзләрен «2014 – 2025 елларга» сүзләренә алыштырырга;

преамбулада «һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеген» сүзләрен «һәм Татарстан Республикасы ведомство максатчан программаларын һәм дәүләт программалары исемлеген» сүзләренә алыштырырга;

1 нче пунктта «2014 – 2022 елларга» сүзләрен «2014 – 2025 елларга» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасында (алга таба – Программа):

Программа исемендә «2014 – 2022 елларга» сүзләрен «2014 – 2025 елларга» сүзләренә алыштырырга;

Программа паспортында:

«Программа исеме» юлында «2014 – 2022 елларга» сүзләрен «2014 – 2025 елларга» сүзләренә алыштырырга;

«Программаның төп эшләүчеләре» юлында «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы» сүзләренә алыштырырга;

«Ярдәмче программалар исемлеге» юлында «2014 – 2022 еллар», «2017 – 2022 еллар», «2019 – 2022 еллар» сүзләрен шул ук эзлеклелектә «2014 – 2025 еллар», «2017 – 2025 еллар», «2019 – 2025 еллар» сүзләренә алыштырырга;

«Программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары | 2014 – 2022 еллар:<br>I этап – 2014 – 2017 еллар;<br>II этап – 2018 – 2021 еллар;<br>III этап – 2022 – 2025 еллар»; |

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr><td rowspan="4">«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре</td><td colspan="2">Программаны финанслауның гомуми күләме Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 25 199,3696 млн.сум тәшкил итә.<br>(млн.сум)</td></tr>
<tr><td>Ел</td><td>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</td></tr>
<tr><td>2014</td><td>1 724,261</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>1 749,3376</td></tr>
</table>

| | | |
|---|---|---|
| | 2016 | 1 924,8585 |
| | 2017 | 1 939,4089 |
| | 2018 | 2 044,4549 |
| | 2019 | 2 188,7229 |
| | 2020 | 2 432,9198 |
| | 2021 | 2 239,8572 |
| | 2022 | 2 238,8872 |
| | 2023 | 2 238,8872 |
| | 2024 | 2 238,8872 |
| | 2025 | 2 238,8872 |
| | Барлыгы | 25 199,3696 |
| | Искәрмә: финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш; | |

«Еллар буенча бүлеп, Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар буенча бүлеп, Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Программа чараларын тормышка ашыру түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>2025 елга 100 мең кешегә кылынган җинаятьләр санын (динамикасын) 1290,0 берәмлеккә кадәр киметү;<br>2025 елга юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булган затлар санын 296 кешегә кадәр киметү;<br>2025 елга сәяси мотивлаштырылган көч куллануны хөкем итүче халык өлешен 95 процентка кадәр арттыру;<br>2025 елга тикшерелгән наркоҗинаятьләрнең гомуми саныннан төркем һәм җинаятьчел берләшмә тарафыннан оештырылган алдан сүз куешу буенча төркем составында кылынган җинаятьләр өлешен 102,3 процентка кадәр арттыру;<br>кадрлар сәясәтенә эчке тикшерүдә тотуны һәм коррупциягә каршы механизмны гамәлгә керткән Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары өлешен 100 процентка кадәр арттыру;<br>2025 елга җирле үзидарә органнары тарафыннан үткәрелгән кулланучылар хокукларын яклау буенча чаралар санын 114 процентка кадәр җиткерү;<br>2025 елга тикшерелгән җинаятьләрнең гомуми санында исерек хәлдә кылынган җинаятьләрнең |

| | |
|---|---|
| | чагыштырма авырлыгын 36,3 процентка кадәр кыскарту;<br>2025 елга эчке эшләр органнарының балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәләрендә исәптә торучы балигъ булмаганнар санын 2700 кешегә кадәр киметү»; |

Программаның 1 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Хәзерге вакытта Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 31 декабрендәге 683 номерлы Указы белән расланган Россия Федерациясенең милли иминлеге буенча яңа стратегия гамәлдә. Әлеге Стратегияне гамәлгә ашыру милли икътисадны үстерүгә, гражданнарның тормыш сыйфатын яхшыртуга, җәмгыятьтә сәяси тотрыклылыкны ныгытуга, ил оборонасын, дәүләт һәм иҗтимагый иминлекне тәэмин итүгә, конкурентлык сәләтен һәм Россия Федерациясенең халыкара абруен күтәрүгә ярдәм итәргә тиеш. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 15 апрелендәге 345 номерлы карары белән «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» дигән Россия Федерациясенең яңа дәүләт программасы расланды. Аның максаты – җинаятьчелеккә каршы торуның, җәмәгать тәртибен, милекне саклауның, иҗтимагый иминлекне һәм юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүнең сыйфатын яхшырту һәм нәтиҗәлелеген күтәрү, шулай ук миграция процессларының нәтиҗәле үсешенә ярдәм итә торган шартлар тудыру.

Югарыда күрсәтелгән максатларга ирешү өчен республика Программасын гамәлгә ашыру дәвам ителә.

2014 – 2017 елларда гамәлгә ашыру йомгаклары буенча 2017 елда 100 мең кешегә җинаятьчелек дәрәҗәсе 1 186,4 җинаять тәшкил итте, аеруча авыр һәм авыр җинаятьләр саны 14,4 процентка (аеруча авыр җинаятьләр – 13 процентка һәм авыр җинаятьләр – 15 процентка) кимеде. Үтерүләр саны 5,47 процентка, сәламәтлеккә аңлы рәвештә авыр зыян салу – 25,28 процентка, үлемгә китергән сәламәтлеккә аңлы рәвештә авыр зыян салу – 47,9 процентка, урлаулар – 11,8 процентка, складлардан, базалардан, кибетләрдән һәм башка сәүдә нокталарыннан – 13,8 процентка, торак урыннардан урлаулар – 27,2 процентка, автомототранспортны урлаулар – 43,5 процентка, талаулар – 25,1 процентка, талау һөҗүмнәре – 23,8 процентка, автотранспортны хокуксыз тартып алу фактлары – 37,2 процентка, яндыру яки шартлау юлы белән милекне аңлы рәвештә юк итү яки зарарлау фактлары – 28 процентка, хулиганлык – 74,1 процентка кимеде.

Планлаштырылган чараларны тулысынча гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә 2 нче ярдәмче программасы һәм «2013 – 2020 елларда юл хәрәкәте иминлеген арттыру» федераль максатчан программасы индикаторларын үтәүнең алга киткән темпларына ирешелде. Юл-транспорт һәлакәтләре аркасында һәлак булучылар саны индикаторы 142,6 процентка; транспорт рискы индикаторы – 141,5 процентка, социаль риск индикаторы – 142,3 процентка үтәлде.

Түбәндәге күрсәткечләр артты: террорчыларны һәм экстремистларны гадел җәзалау чарасы буларак бәяләүче халыкның өлеше 60 процентка кадәр; хокук саклау органнарының террорчылык һәм экстремизм күренешләре белән көрәшен җитәрлек чаралар буларак бәяләүче халыкның өлеше 50 процентка кадәр; сәяси мо-

тивлаштырылган көч куллануны гаепләүче халыкның өлеше 82 процентка кадәр; мәгариф оешмаларында деструктив йогынтыга җитәрлек иммунитеты булган белем алучылар өлешен 72 процентка кадәр.»;

Программаның 2 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Программаның төп максаты һәм бурычлары.
Программаның көтелә торган соңгы нәтиҗәләре тасвирламасы,
аны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары

Программаның максаты булып Татарстан Республикасында җинаятьчелеккә каршы торуның сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген арттыру, җәмәгать тәртибен саклау һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итү тора.

Программа максатына ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:

Татарстан Республикасында хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау эшчәнлеген камилләштерү;

юл-транспорт һәлакәтләреннән үлүчеләр һәм зыян күрүчеләр белән юл-транспорт һәлакәтләре санын киметү;

Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче гражданнарның тормыш дәрәҗәсен һәм тынычлыгын, экстремизм һәм терроризмга каршы тору нигезендә аларның законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау, аларның чагылышларын профилактикалау һәм кисәтү дәрәҗәсен күтәрү;

Татарстан Республикасында наркотикларның законсыз таралу һәм медицина булмаган куллану масштабларын киметү;

коррупциянең сәбәпләрен ачыклау һәм бетерү, аның күренешләренә ярдәм итүче шартларга каршы тору, җәмгыятьтә коррупциягә карата түзеп торырлык караш формалаштыру;

Татарстан Республикасында Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән кулланучылар хокукларын нәтиҗәле яклау өчен шартлар тудыру, товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләрне куллану базарын үстерү;

Татарстан Республикасы халкы арасында алкогольле продукцияне чамадан тыш куллану масштабларын киметү һәм алкоголизмны профилактикалау;

балигъ булмаганнар арасында караучысызлыкны, хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау, шулай ук аларның хокукларын яклау эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру.

Программа бурычларын хәл итү өчен түбәндәге чараларны тормышка ашыру каралган:

Татарстан Республикасы территориясендә җинаятьчелек дәрәҗәсен киметү;

зыян күрүчеләр белән юл-транспорт һәлакәте һәм юл-транспорт һәлакәте нәтиҗәсендә һәлак булучылар санын киметү;

Татарстан Республикасы территориясендә терроризмга һәм экстремизмга каршы тору һәм яшәүче гражданнарның гомерен саклау;

наркотикларның законсыз әйләнешен кисәтү буенча хокук саклау органнары эшенең нәтиҗәлелеген арттыру;

Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору буенча эшчәнлекне оештыруны камилләштерү;

Татарстан Республикасында Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән кулланучылар хокукларын нәтиҗәле яклау шартларын булдыру;

халык тарафыннан алкогольле продукцияне куллануның гомуми дәрәҗәсен киметү.

Программа чараларының нәтиҗәлелеген бәяләү өчен түбәндәге күрсәткечләрне кулланырга тәкъдим ителә:

җинаятьләр саны (динамикасы);

тикшерелгән җинаятьләрнең гомуми санында элек хөкем ителгән затлар тарафыннан кылынган җинаятьләрнең чагыштырма авырлыгы;

юл-транспорт һәлакәтендә һәлак булучылар саны;

хокук саклау органнарының терроризм һәм экстремизм күренешләренә каршы тиешле көрәш чаралары буларак бәяләүче халык өлеше;

тикшерелгән наркоҗинаятьләрнең гомуми санынннан авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр тикшерелгән өлеше;

кадрлар сәясәтенә эчке контроль һәм коррупциягә каршы механизм керткән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары өлеше;

кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын бозу фактлары буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре саны;

тикшерелгән җинаятьләрнең гомуми санында алкоголь исереклеге хәлендә кылынган җинаятьләрнең чагыштырмача зурлыгы.

Программаны тормышка ашыру вакыты – 2014 – 2025 еллар (өч этапта):

I этап – 2014 – 2017 еллар;

II этап – 2018 – 2021 еллар;

III этап – 2012 – 2025 еллар.

Программаның төп максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары, шулай ук Программада каралган чараларны финанслау аңа теркәлгән 1 нче һәм 2 нче кушымталарда китерелә.»;

Программаның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программаны финанслауның гомуми күләме Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 25 199,3696 млн.сум тәшкил итә.

(млн.сум)

| Ел | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы |
|---|---|
| 2014 | 1 724,261 |
| 2015 | 1 749,3376 |
| 2016 | 1 924,8585 |
| 2017 | 1 939,4089 |
| 2018 | 2 044,4549 |
| 2019 | 2 188,7229 |
| 2020 | 2 432,9198 |
| 2021 | 2 239,8572 |
| 2022 | 2 238,8872 |
| 2023 | 2 238,8872 |
| 2024 | 2 238,8872 |

| | |
|---|---|
| 2025 | 2 238,8872 |
| Барлыгы | 25 199,3696 |

Программа чараларын тормышка ашыру өчен чараларны үтәүчеләрнең төп эшчәнлеген финанслауга бүлеп бирелә торган акчаны куллану күздә тотыла.

Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм, Татарстан Республикасы бюджеты һәм федераль бюджет мөмкинлекләреннән чыгып, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен билгеләнгән тәртиптә тәгаенләнергә тиеш.»;

4 бүлекнең бишенче абзацында «һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеге» сүзләрен «һәм Татарстан Республикасы ведомство максатчан программалары һәм дәүләт программалары исемлеге» сүзләренә алыштырырга;

Программага теркәлгән 1 нче, 2 нче кушымталарны яңа редакциядә (карарга теркәләләр) бәян итәргә.

«2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау буенча эшчәнлекне оештыру», «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру», «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында террорчылык һәм экстремизмны профилактикалау», «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасы халкы арасында наркоманияне профилактикалау», «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында кулланучылар хокукларын яклау комплекслы системасын үстерү», «2017 – 2022 елларга Татарстан Республикасында алкоголь продукциясен күп куллану масштабларын киметү һәм алкоголизмны профилактикалау», «2019 – 2022 елларга Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау» ярдәмче программаларын шул ук эзлеклелектә 1 – 7 нче кушымталар нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин